1



Бер

Бер саны 1 цифры белән күрсәтелә.

Бер кояш, бер ай, бер әни, бер әти була. Без яшәгән Җир шары, күк йөзе берәү, хәтта син үзең дә бер генә. Ә хәзер уенчыкларыңа кара. Алар бик күп. Шул уенчыклар арасыннан бер яраткан уенчыгыңны ал. Менә күрдеңме, син инде бер санын аерырга өйрәндең. Уенчыкларың күп, ә яратканы бер генә.

? Тәлинкәдә биш коймак бар иде. Дәү әниләре Динәгә, Ләйлә, Алсу, Кәрим, Мансурга берәр коймак бирде. Тәлинкәдә ничә коймак калды? *(Берәү дә калмады)*

Рәсемгә кара. Кечкенә турыпочмаклык эчендә ничә түгәрәк бар? *(Бер түгәрәк)* Зур турыпочмаклык эчендә ничә түгәрәк? *(Күп)*



Бер гаилә

Барыбыз да бертуган без,
Бер гаилә — өебез!
Барыбыз да бертуган без,
Бер гаилә — илебез!
Бертуган без!
Бер гаилә
Булсын иде җиребез!

(Роберт Миңнуллин)

Ике туган: берсе ак булган, берсе кара булган. *(Көн һәм төн)*

2

И-ке

Ике саны 2 цифры белән күрсәтелә.

Курчагыңа кара әле. Аның ике кулы, ике аягы, ике күзе, ике колагы бар. Кешеләрнең дә шулай. Синең дә, әти-әниеңнең дә куллары, аяклары, колаклары, күзләре икәү. Инде үзеңнең колакларыңны, аяк, кул, күзләреңне күрсәтеп чык. Алар ничәү? *(Бала саный.)* Син, урамга чыкканда, ике кулыңа ике бияләй, ике аягыңа ике аяк киеме киясең.

? Динә өстәлдәге вазадан бер конфет алды. Чәй эчкәндә, аңа әнисе тагын бер конфет бирде. Динәнең барлыгы ничә конфеты булды? *(Ике конфеты)*

Карточканың алгы ягына ясалган рәсемгә кара. Рәсемдә ничә курчак күрәсең? *(Ике курчак)* Аларның күлмәкләре нинди төстә? *(Ал һәм зәңгәр)*

Тугансыз күңелсез

Без — бертуган,
Икебез —
Ике бериш кеше без...
Без — апалы-сеңелле,
Безгә бергә күңелле.
Кемнәрнең апасы юк,
Кемнәрнең сеңлесе юк —
Кыендыр, күңелсездер,
Алар сез түгелсездер?!

(Эльмира Шәрифуллина)

Бер тау тирәли ике тишек чүмеч эленгән. *(Колаклар)*